СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2022 Баулы шәһәре №138

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте

өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 176 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 274 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 90 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 2 һәм 3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләмнәре авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи оклады күләменә бермә-бер мәртәбә исәпләнә;

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи окладры күләме 11 958 сум тәшкил итә.»;

2 нче кушымтаны яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе — И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның 20 апрелендәге
149 номерлы карарына кушымта

(Баулы муниципаль районы Советының

2022 елның ______ __________
_______ номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль район башлыгының, муниципаль район башлыгы урынбасарының, муниципаль район контроль-хисап палатасы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының акчалата түләү күләмнәре

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 группа |
| Муниципаль район башлыгы | 33 245,0 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 29 918,0 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 29 918,0 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 26 906,0 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 21 765,0 |